КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 август

г.Казань

№ 644

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән расланган «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 ноябрь, 1005 нче; 2020 ел, 24 ноябрь, 1057 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1118 нче; 2022 ел, 24 март, 267 нче, 2022 ел, 16 сентябрь, 1008 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 131 статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны финанслау максатларында Фонд милкенә Татарстан Республикасы мөлкәти кертеме рәвешендә бирелә (алга таба - Субсидия). Субсидия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында

һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 131 статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны финанслау турында яки финанслауның максатчан булмавы хакында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1192 нче карары белән расланган бертип форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә (алга таба - Килешү).»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия Фондның Килешү төзелгән айга кадәрге айның 1 числосына түбәндәге таләпләргә туры килүе шарты белән бирелә:»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, Фондка карата банкротлык процессы билгеләнмәсә, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

41 пунктта:

икенче абзацта «(алга таба - Карар кабул итү кагыйдәләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фондның Министрлык тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә Субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

12 пунктның беренче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе һәм аңа ирешү вакыты Килешүдә билгеләнә.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү срогы башланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча Фондның бу Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешүе турындагы хисапны Министрлыкка кертә.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Министрлык Фондның Субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

17 пунктта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

20 пунктта «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин